ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

10 август 2023 ел

№ 7253

Башкарма комитетның 2014 елның 17 октябрендәге 6384 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә бакчачылык-яшелчәчелек участокларында һәм йорт яны хуҗалыкларында үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сезонлы киңәйтелгән сату урыннары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясының 11 өлешенең 4, 11 пунктлары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә бакчачылык-яшелчәчелек участокларында һәм йорт яны хуҗалыкларында үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сезонлы киңәйтелгән сату урыннары исемлеген раслау турында» 2014 елның 17 октябрендәге 6384 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2018 елның 25 маендагы 2947 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге 6503 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге 2700 номерлы, 2021 елның 6 августындагы 5206 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә бакчачылык-яшелчәчелек участокларында һәм йорт яны хуҗалыкларында үстерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сезонлы киңәйтелгән сату урыннары исемлегенә, түбәндәге редакциядә 21.1 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| «21.1. | Шамил Усманов урамы, 41/17 торак йорт каршында | Үзәк районы хакимияте» |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов